КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 4 октябрь г.Казань № 1229

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Мәдәният, сәнгать, кинематография, анимация, мәдәни мирасны популярлаштыру, дәүләт милли сәясәте, халыкара хезмәттәшлек өлкәсендә проектларны гамәлгә ашыруга, чаралар оештыруга һәм уздыруга, Россия Федерациясендә һәм дөньякүләм киңлектә татар мәдәниятен популярлаштыруга, сугыш елларында хәбәрсез югалган дип саналган Татарстан АССРда туучыларны һәм анда яшәүчеләрне эзләү эшләрен башкаруга бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итүгә (каплауга) коммерцияле булмаган оешмаларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2021 ел, 16 август, 732 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Мәдәният, сәнгать, кинематография, анимация, мәдәни мирасны популярлаштыру, дәүләт милли сәясәте, халыкара хезмәттәшлек өлкәсендә проектларны гамәлгә ашыруга, чаралар оештыруга һәм уздыруга, Россия Федерациясендә һәм дөньякүләм киңлектә татар мәдәниятен популярлаштыруга, сугыш елларында хәбәрсез югалган дип саналган Татарстан АССРда туучыларны һәм анда яшәүчеләрне эзләү эшләрен башкаруга

бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итүгә (каплауга) коммерцияле булмаган оешмаларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2021 ел, 16 август, 732 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 ел, 16 декабрь, 1240 нчы; 2022 ел, 15 июль, 678 нче; 2023 ел, 1 март, 193 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

исеменә «халыкара» сүзеннән соң «, төбәкара» сүзен өстәргә;

1 пунктка «халыкара» сүзеннән соң «, төбәкара» сүзен өстәргә;

әлеге карар белән расланган Мәдәният, сәнгать, кинематография, анимация, мәдәни мирасны популярлаштыру, дәүләт милли сәясәте, халыкара хезмәттәшлек өлкәсендә проектларны гамәлгә ашыруга, чаралар оештыруга һәм уздыруга, Россия Федерациясендә һәм дөньякүләм киңлектә татар мәдәниятен популярлаштыруга, сугыш елларында хәбәрсез югалган дип саналган Татарстан АССРда туучыларны һәм анда яшәүчеләрне эзләү эшләрен башкаруга бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итүгә (каплауга) коммерцияле булмаган оешмаларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибендә:

исеменә «халыкара» сүзеннән соң «, төбәкара» сүзен өстәргә;

1 пунктның беренче абзацына «халыкара» сүзеннән соң «, төбәкара» сүзен өстәргә;

15 пунктта «өч» сүзен «ун» сүзенә алмаштырырга;

17 пунктта «өченче» сүзен «унынчы» сүзенә алмаштырырга;

әлеге Тәртип кушымтасының башисеменә «халыкара» сүзеннән соң «, төбәкара» сүзен өстәргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин